**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 10.05.2023** **№ 571**

# Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләсен карау өчен гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 37, 39 статьяларына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставына таянып, халыкның фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 июненә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләсен карау өчен гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә, атап әйткәндә – Фәйзутдинов Тимур Мансурович милкендәге 1000 квадрат метр мәйданлы 16:16:080507:2827 кадастр номерлы җир кишәрлеген «авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен» рөхсәт ителгән файдалану төреннән «Кибетләр» төренә, 14 сәгать 00 минутта, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау ав., Юбилей ур., 1А й., Биектау авыл җирлеге администрациясе бинасында.

2. Кызыксынучы затка «Биектау хәбәрләре» газетасында җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрелү урыны һәм вакыты турында мәгълүматны бастырып чыгару белән бәйле чыгымнарны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясының 10 пункты нигезендә үз өстенә алырга.

3. Гавами тыңлауларда каралырга тиешле мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне кабул итүне Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл. станциясе п., Совет ур., 13 йорт, 209 каб. адресы буенча эш көннәрендә көн саен 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр 2023 елның 09 маеннан 2023 елның 1 июненә кадәр чорда һәм шулай ук 2023 елның 1 июнендә турыдан-туры гавами тыңлаулар уздырганда гамәлгә ашырырга.

4. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1) Хәбибуллин А.А. - Биектау авыл җирлеге башлыгы – Рәислек итүче;

2) Арсланова В.Н. - Биектау авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Секретарь;

3) Дамоцев И.С. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге баш белгече;

4) Хидиятуллин М.Ф. - Биектау авыл җирлеге депутаты;

5) Садреев З.З. - Биектау авыл җирлеге депутаты.

5. Эш төркеменә катнаш кишәрлекләр милекчеләренә хәбәр итәргә (Форма кушымтада бирелә).

6. Эш төркеменә Биектау муниципаль районы территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча беркетмә һәм бәяләмә әзерләп җибәрергә.

7. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм ТКХ буенча урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Хәбәрнамә

Хөрмәтле ___________________________!

Сезгә ____ ___ елның ______ ____ сәгатьтә _________________ авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында: ____________________________________________ ____________________ ______ адресы буенча, _________________ кадастр номерлы, ______________________ ___________ милкендәге җир кишәрлегенең _____________________________________ ___ мәсьәләсе буенча, Сез катнаш кишәрлек милекчесе булып торуыгыз сәбәпле, гавами тыңлаулар үткәрелүе турында хәбәр итәбез.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне язма рәвештә кабул итү Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл. станциясе п., Совет ур., 13 йорт, 209 каб., адресы буенча эш көннәрендә көн саен 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр _____ елның __________ нан ______ елның __________ кадәр чорда һәм шулай ук 2023 елның __________ турыдан-туры гавами тыңлаулар уздырганда гамәлгә ашырыла.

Гавами тыңлауларда катнашу өчен үзең белән паспорт алырга кирәк.

Барлык туган сораулар буенча 8-84365-23068 телефоны аша яисә Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл станциясе п., Кооператив ур., 5 й. адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

**Хәбәрнамәне алды:**

**Дата________________**

**Ф.И.А. __________________________________**

**Имза_______________________**